СОВЕТ
АРХАНГЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423182, РТ, Новошешминский район,
село Слобода Архангельская,
улица Горького, 21а

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АРХАНГЕЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
423182, ТР, Яңа Чишмә районы,
Архангел Бистәсе авылы,
Горький урамы, 21а

тел.: (8-84348) 38-0-40, факс: (8-84348) 38-0-40, Arhan.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районы Архангельск авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2024 елның 28 нче феврале № 52-166

## Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Архангельск авыл Советының «Җир салымы турында» 24.11.2016 № 18-44 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Архангельск авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Архангельск авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Архангельск авыл Советының «Җир салымы турында» 24.11.2016 № 18-44 номерлы карарына (5.09.2017 № 32-66; 13.11.2018 № 49-99; 23.09.2019 № 60-130; 20.10.2020 № 3-8; 12.03.2021 № 8-22; 18.12.2023 № 40-135; 27.11.2024 № 48-156; карарлар редакциясендә) (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Караның 3.2 нче пунктның икенче абзацында «оешмаларга һәм» сүзләрен «муниципаль» сүзенә алмаштырырга;

1.2. Карарны түбәндәге эчтәлекле 4 пункт белән өстәргә:

«4. Салым түләүчеләр - үзләренә карата хисап чоры квартал буларак билгеләнгән юридик затлар агымдагы салым чорының беренче, икенче һәм өченче кварталлары тәмамланганнан соң салым буенча аванс түләүләре суммаларын җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлешенең тиешле салым ставкасының дүрттән бере итеп исәплиләр.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында»: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Архангельск авыл җирлеге башлыгы Н.А.Сердюк